Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында гражданнар җыены

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлегенең Монай
торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

28.11.2024 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 18 ноябрендәге 3 номерлы карары белән 2024 елның 28 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 360 катнашучы, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан катнашучылар саны - 188 кеше. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 188 катнашучы тавыш бирде; «каршы» позициясе өчен 0. Бәян ителгәннәр нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай торак пункты гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлегенең Монай авылында гражданнар җыенын узган дип санарга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, свода катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары , югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорауны расларга:

«1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны ремонтлау (Төзүчеләр, Төньяк, Йолдыз, Ленин урамнарына вак таш түшәү, Төзүчеләр, Монтажчылар урамындагы юл өслегендә булган чокырларны ремонтлау, транспорт хезмәтләре күрсәтү (автогрейдер хезмәтләре күрсәтү)”.

3. Әлеге карарны Монай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Монай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге башлыгы ________________ Р.М.Кириллов
(имза) (имзаның аңлатмасы)